# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## 2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында

16.12.2024 ел № 10

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай торак пунктында 2024 елның 22 ноябрендәге 5 номерлы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында”гы, 2024 елның 22 ноябрендәге 6 номерлы “2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында”гы карарларына үзгәрешләр кертү буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Советы башлыгының 2024 елның 07 декабрендәге 9 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылы гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай торак пунктында 2024 елның 22 ноябрендәге 5 номерлы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында”гы, 2024 елның 22 ноябрендәге 6 номерлы “2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында”гы карарларына үзгәрешләр кертергә һәм чараларны түбәндәгечә бәян итәргә:

1) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау ( Турай торак пунктына тирәннән су алу насосы сатып алу, Турай торак пунктындагы яңа су җыю башнясына санитар саклау зонасын киртәләү өчен материал сатып алу, яңа су җыю башнясына санитар саклау зонасын киртәләү)

2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү ( Турай торак пунктында үлән чабу өчен триммер сатып алу; МТЗ 82.1 тракторы өчен МТЗ

82.1 тракторы өчен үлән чапкычы, арба сатып алу, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү.)

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Турай торак пунктында кышкы чорда юлларны кардан чистарту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү); юл өслеге өчен вак таш сатып алу ; транспорт хезмәтләре.)

4) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (1 ( бер ) данә янгын сүндерү гидрантларын сатып алу, Турай торак пунктының Крайняя урамында 1(бер) данә янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру.)

5) һәйкәлләрне төзекләндерү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Турай авылында махсус хәрби операциядә һәм Әфганстанда катнашучыларга һәйкәлләр кую.)

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Турай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Турай авыл җирлеге башлыгы ______________ Г.Б.Куляшова
(имза) (имзаның аңлатмасы)